| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ГЛАВА БИЗЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>Ул.Центральная, д.46, с.Бизяки,<br>Менделеевский район, Республика<br>Татарстан, 423648 | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ БӘЗӘКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ<br>Үзәк урам, 46 йорт,<br>Бәзәкә авылы, Менделеевск районы,<br>Татарстан Республикасы,423648 |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 6 13.06.2024 ел

Менделеевск муниципаль районы
Бәзәкә авыл җирлегенең Бәзәкә авылында
гражданнарның үзара салым акчаларын
куллану мәсьәләсе буенча гражданнар
җыенын билгеләү турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясына ярашлы рәвештә КАРАР БИРӘМ:

1. 2024 елның 22 июнендә 10 сәгать 00 минутка Бәзәкә авыл җирлегенең Бәзәкә авылында гражданнарның үзара салым акчаларын куллану буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. 2024 елның 22 июнендә 13 сәгать 00 минутка Бәзәкә авыл җирлегенең Бәзәкә авылында гражданнарның үзара салым акчаларын куллану буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. 2024 елның 22 июнендә 16 сәгать 00 минутка Бәзәкә авыл җирлегенең Бәзәкә авылында гражданнарның үзара салым акчаларын куллану буенча гражданнар җыенының өченче этабын билгеләргә.

4. Бәзәкә авыл җирлеге җыеннарының барлык этапларын үткәрү урыны:
1 этап: Бәзәкә авылы, Яңа урам, 1 йорт, авыл мәдәният йорты
2 этап: Бәзәкә авылы , Үзәк урам, 46 йорт, административ бина
3 этап: Бәзәкә авылы , Яр буе урамы

5. Бәзәкә авылында яшәүчеләрнең исемлеген җыеннар этапларына бүлү территориаль билге буенча түбәндәге тәртиптә башкарыла:
1 этап: Яшьләр ур., 1 -126 й.,Елга аръягы ур. 1-106 й.,Яәа ур., 1 -36 й.
2 этап: Үзәк ур. 1 -102 й.
3 этап: Яр буе урамы 1 -36 й.,
Дуслык ур., 1 -14 й., Бакча ур. 1 -11,
РифкатьТаҗиев ур. 4,7 й.; Урман ур.10 й.

6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
"Сез гражданнар җыеннарының 2023 елның 24 ноябрендәге 1,2 номерлы карарлары буенча җыелган үзара салым акчаларының бер өлешен кулланырга ризамы:
- Торак пункт территориясен төзекләндерү МТЗ 82.1 тракторын сатып алуны финанслау.
- Торак пункт территориясен төзекләндерү (Трактор өчен асмалы җиһазлар сатып алу»
« РИЗА» «КАРШЫ»

7. Әлеге карарны Менделеевск муниципаль районының мәгълүмат стендларында һәм рәсми сайтында урнаштырырга www.mendeleevsk.tatar.ru "Бәзәкә авыл җирлеге" бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында pravo.tatarstan.ru бастырырга

8. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Бәзәкә авыл җирлеге башлыгы: И.И. Кәшәфетдинов